ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 35

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«01» 03 2022 ел.

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар тапшыру тәртибен раслау турында

Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан капиталь ремонт фондларын формалаштыруны тикшерүдә тотуны тәэмин итү максатларында **боерык бирәм:**

1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар тапшыру тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга (кушымтада бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар тапшыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 30 октябрендәге 431 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 30 октябрендәге 431 номерлы боерыгы белән расланган Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан

Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар тапшыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 13 сентябрендәге 124 номерлы боерыкларын көчләрен югалткан дип танырга.

3. Районара торак инспекцияләре җитәкчеләренә, Казан шәһәре торак инспекциясе җитәкчесенә, Үзәк инспекторлык бүлеге җитәкчесенә Тәртиптә каралган белешмәләр тапшырылуын тикшерүдә тоту бурычын йөкләргә.

4. Районара торак инспекцияләре җитәкчеләренә, Казан шәһәре торак инспекциясе җитәкчесенә, Үзәк инспекторлык бүлеге җитәкчесенә хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 нчы көненә кадәр квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең торак фондына капиталь ремонт ясауны тикшерүдә тоту бүлегенә 2, 3, 4 нче кушымталарның билгеләнгән үрнәкләре нигезендә махсус счет хуҗаларыннан алынган җыелма мәгълүматны тапшырырга.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең торак фондына капиталь ремонт ясауны тикшерүдә тоту бүлегенә мәгълүматның үз вакытында тапшырылуын һәм аның тулылыгын тикшереп торуны районара торак инспекцияләре җитәкчеләренә, Казан шәһәре торак инспекциясе җитәкчесенә, Үзәк инспекторлык бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясе җитәкчесенең
2022 елның 03.01 № 35
боерыгы белән расланды

# КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРДА ГОМУМИ МӨЛКӘТКӘ КАПИТАЛЬ РЕМОНТ ЯСАУНЫ ТӘЭМИН ИТҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ЭШЧӘНЛЕКНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ МАХСУСЛАШТЫРЫЛГАН КОММЕРЦИЯСЕЗ ОЕШМА (ТӨБӘК ОПЕРАТОРЫ) ҺӘМ МАХСУС СЧЕТ ХУҖАСЫ ТАРАФЫННАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕНӘ МӘГЪЛҮМАТЛАР ТАПШЫРУ ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциясез оешма (төбәк операторы) һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә (алга таба – ТР ДТИ) мәгълүматлар тапшыруның әлеге тәртибе «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы закон) 12 статьясын үтәү максатында эшләнде.

1.2. Тәртиптә түбәндәге төп терминнар һәм төшенчәләр кулланыла:

махсуслаштырылган коммерциясез оешма – фондның оешту-хокук рәвешендә төзелгән юридик зат, аның функцияләре Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясында билгеләнгән (алга таба – төбәк операторы);

махсус счет хуҗасы – күпфатирлы йорт белән идарә итүче һәм бер күпфатирлы йортта яки берничә күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының (алга таба – РФ Торак кодексы) 136 статьясының 2 өлешендәге 1 пункты нигезендә төзелгән торак милекчеләре ширкәте, күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы торак кооперативы, идарә итү шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы идарәче оешма, төбәк операторы;

ТР ТФМ ДМС (Татарстан Республикасы торак фонды мониторингы дәүләт мәгълүмат системасы) – торак фонды турында мәгълүматны җыю, эшкәртү, саклау, бирү, урнаштыру һәм куллану, күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондларын төбәк операторы счетында һәм махсус счетта формалаштыру, шулай ук торак-коммуналь хуҗалык белән бәйле башка мәгълүматны җыю, эшкәртү, саклау, урнаштыру һәм куллануны тәэмин итә торган программа, техник чаралар һәм мәгълүмат технологияләре нигезендә эшли торган Татарстан Республикасының мәгълүмат системасы;

капиталь ремонт фонды – күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен түләнгән кертемнәр, капиталь ремонт өчен

кертемнәрне түләү бурычын тиешенчә үтәмәгән өчен мондый биналарның милекчеләре тарафыннан түләнгән пенялар, капиталь ремонт фондлары формалаштырыла торган махсус счетта, счетта, төбәк операторы счетларында булган акчалардан файдаланган өчен исәпләнгән процентлар, капиталь ремонт фонды акчаларын, РФ Торак кодексының 191 статьясы нигезендә бирелгән финанс ярдәме акчаларын урнаштырудан алынган керемнәр, шулай ук күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыру өчен җәлеп ителгән кредит һәм (яки) бурычка алынган акча чаралары;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру – капиталь ремонт фондын махсус счетта торучы акчалар рәвешендә капиталь ремонт фондын формалаштыру максатларында капиталь ремонт өчен кертемнәрне махсус счетка күчерү, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең төбәк операторына карата мәҗбүри хокуклары рәвешендә капиталь ремонт фондын формалаштыру максатларында төбәк операторы счетына капиталь ремонт өчен кертемнәр күчерү;

биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган махсус счетта фонд формалаштыру ысулы турында белдерү – тиешле күпфатирлы йортта махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыруның биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган ысулы турында хәбәрне үз эченә алган, имзаланган һәм мөһер белән таныкланган документ, аны махсус счет хуҗасы махсус счетны ачкан мизгелдән башлап биш эш көне эчендә билгеләнгән үрнәк нигезендә, мәҗбүри тәртиптә биналарның милекчеләренең гомуми җыелышының РФ Торак кодексының 170 статьясының 3 һәм 4 өлешләрендә каралган карарларны кабул итүе турында беркетмә күчермәсен һәм махсус счет ачу турында банк белешмәсе күчермәсен теркәп, ТР ДТИ тапшырырга тиеш;

махсус счет ачу турында хәбәр – махсус счет ачу турында банк белешмәсенең күчермәсе, ул, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре сайлап алган капиталь ремонт фондын махсус счетта формалаштыру ысулы турында хәбәр белән бергә, әлеге белешмәләр банк белешмәсендә булмаган очракта, капиталь ремонт фондын формалаштыру өчен нәкъ менә максатчан счет ачылуны раслаучы документларны теркәп, ТР ДТИ җибәрелә;

белдерүләр реестры – күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан сайлап алынган капиталь ремонт фондын махсус исәптә формалаштыру ысулы турында белдерүләр реестры;

махсус счетлар реестры – капиталь ремонт фондын формалаштыру өчен ачылган махсус счетлар реестры;

капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы сайланмаган күпфатирлы йортлар турында белешмәләр – ТР ДТФ ДМС системасыннан алынган, биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайламаган һәм (яки) аны гамәлгә ашырмаган күпфатирлы йортлар турында ТР ДТИ тарафыннан җирле үзидарә органына һәм төбәк операторына җибәрелә торган мәгълүмат.

## 2. ТР ДТИ тарафыннан күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру турында махсус счет хуҗасы тарафыннан мәгълүмат бирү тәртибе

2.1. Махсус счет хуҗасы махсус счет ачылганнан соң биш эш көне эчендә ТР ДТИ кәгазь чыганакта түбәндәгеләрне тапшыра:

– күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан сайлап алынган капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турында белдерү (1 нче кушымта);

– әлеге күпфатирлы йорт биналары милекчеләренең капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау буенча карар кабул итү турында гомуми җыелыш беркетмәсенең күчермәсе;

– махсус счет ачу турында банк белешмәсе;

– күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында бина милекчеләренең гомуми җыелышының беркетмәсе күчермәсе;

– күпфатирлы йорт турында мәгълүмат (катлары, күп фатирлы йортның гомуми мәйданы, күп фатирлы йорттагы торак биналарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, файдалануга тапшыру елы, соңгы капиталь ремонт ясау елы).

2.2. Капиталь ремонт фондын махсус счетта формалаштыру турындагы карар махсус счетны ачу һәм махсус счет хуҗасы тарафыннан РФ Торак кодексының 172 статьясының 1 өлешендә каралган документларны ТР ДТИ тапшыру шарты белән гамәлгә ашырылган дип санала.

Төбәк операторы исеменә ачылган махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыру турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында, тиешле гомуми җыелыш үткәрүне башлап җибәргән зат, РФ Торак кодексының 170 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, төбәк операторы адресына әлеге карар рәсмиләштерелгән милекчеләрнең гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсен җибәрә.

2.3. Күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләрен рәсмиләштерүгә карата таләпләр һәм Күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары карарлары һәм беркетмәләренең төп нөсхәләрен Россия Федерациясе субъектларының дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыра торган вәкаләтле башкарма хакимият органнарына җибәрү тәртибен раслау турында» 2019 елның 28 гыйнварындагы 44/пр номерлы боерыгы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.

2.4. Тапшырылган белешмәләр ТР ДТИ (районара торак инспекцияләре, Казан шәһәре торак инспекциясе, Үзәк инспекторлык бүлеге) тарафыннан ТР ДТФ ДМС системасына кертелә.

2.5. Махсус счетларның хуҗалары тарафыннан тапшырылган белешмәләр нигезендә, ТР ДТИ белдерүләр реестрын, махсус счетлар реестрын алып бара (2 нче, 3 нче кушымталар).

2.6. Махсус счет хуҗасы ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр кәгазь чыганакта, шулай ук Excel форматында электрон рәвештә электрон почта аша ТР ДТИ түбәндәге белешмәләрне тапшыра (4 нче кушымта):

– капиталь ремонт өчен кертем сыйфатында исәпләнгән акчалар күләме турында мәгълүмат;

– капиталь ремонтка кертем сыйфатында күчкән акчалар күләме турында

мәгълүмат;

– капиталь ремонт өчен махсус счеттан тотылган акчалар күләме турында мәгълүмат;

– махсус счетта калган акча күләме турында мәгълүмат;

– займ шартнамәсен һәм (яки) капиталь ремонт үткәрүгә кредит шартнамәсен төзү турында мәгълүмат, мондый шартнамәләрнең расланган күчермәләрен теркәп.

2.7. Әгәр күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре төбәк операторы счетында капиталь ремонт фондын төзүне туктату һәм махсус счетта капиталь ремонт фондын булдыру турында карар кабул итсә, махсус счет хуҗасы кәгазь чыганакта ТР ДТИ түбәндәгеләрне тапшыра:

– күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан сайлап алынган капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турында белдерү (1 нче кушымта);

– әлеге күпфатирлы йорт биналары милекчеләренең капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау буенча карар кабул итү турында гомуми җыелыш беркетмәсенең күчермәсе;

– махсус счет ачу турында банк белешмәсе;

– күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында бина милекчеләренең гомуми җыелышының беркетмәсе күчермәсе;

– күпфатирлы йорт турында мәгълүмат (катлары, күп фатирлы йортның гомуми мәйданы, күп фатирлы йорттагы торак биналарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлгән гражданнар саны, файдалануга тапшыру елы, соңгы капиталь ремонт ясау елы).

## 3. ТР ДТИ тарафыннан күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру турында төбәк операторы тарафыннан мәгълүмат бирү тәртибе

3.1. Төбәк операторы махсус счет хуҗасы булып торган очракта, ТР ДТИ мәгълүмат бирү әлеге боерыкның 2 бүлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.2. Төбәк операторы биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондларын счетта, төбәк операторы счетларында формалаштыра торган күпфатирлы йортлар, шулай ук мондый күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләреннән капиталь ремонтка кертелгән акчаларның күчүе турында, шул исәптән ТР ТФМ ДМС аша да, ТР ДТИ белешмәләр тапшырырга тиеш.

## 4. Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру буенча ТР ДТИ мәгълүматлар тапшыру

4.1. Капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турында карар кабул итү һәм сайланган ысулны гамәлгә ашыру өчен 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы законның 2 статьясының $4^1$ өлешендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карарының 2 пунктында билгеләнгән вакытлар узып киткәч, ТР ДТИ милекчеләре капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайламаган һәм (яки) аны гамәлгә ашырмаган күпфатирлы йортлар турында ТР ТФМ ДМС системасыннан алынган мәгълүматны кушымтада (5

нче кушымта) бирелгән үрнәк буенча җирле үзидарә органнарына һәм төбәк операторына җибәрә.

4.2. Әгәр күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайламасалар яисә алар сайлаган ысул закон белән билгеләнгән чорда гамәлгә ашырылмаса, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органы мондый йортка карата төбәк операторы счетында капиталь ремонт фондын формалаштыру турында карар кабул итә.

4.3. ТР ДТИ капиталь ремонт фондын формалаштыру турында мәгълүматны Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсеше, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органына башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән тәртиптә һәм чорларда тапшыра.

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенә ________________________________________
(почта адресы)

Махсус счет хуҗасыннан яисә күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен төбәк операторы исеменә ачылган махсус счет хуҗасыннан белдерү, түбәндәге адрес буенча:
________________________________________,
махсус банк счетын ачу турында
(счет ачылган көннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә)

«__» ____________ 20__ ел.

Оешу-хокук формасы: ________________________________________
________________________________________
Махсус счет хуҗасы: ________________________________________
________________________________________
(оешманың тулы исеме)
ИНН ____________________ КПП ____________________
ОКТМО ____________________ ОГРН ____________________
Махсус банк счетын ачу турында хәбәр итә:
Банк ________________________________________
(банкның тулы исеме)
Банкның ИНН ____________________
Банкның КПП ____________________
Банкның ОГРН ____________________
Банкның БИК ____________________
Банкның корреспондент счеты ____________________
Махсус счет номеры ____________________
Махсус счетны ачу көне
«__» __________ 20__ ел.

Оешма җитәкчесе
махсус счет хуҗасы ________________________________________
________________________________________
(вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме, имза)
мөһер урыны

Кушымта:
1. Әлеге күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау буенча карар кабул итү турында гомуми җыелыш беркетмәсе күчермәсе, 1 нөсхәдә.
2. Махсус счет ачу турында банк белешмәсе, 1 нөсхәдә.
3. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында бина милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе күчермәсе, 1 нөсхәдә;
4. Күпфатирлы йорт турында мәгълүмат, 1 нөсхәдә.

2 нче кушымта

Биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын формалаштыру буенча сайланган ысул турында белдерүләр реестры,
20___ елның «__» __________ торышына хисап

| Муниципаль берәмлек | Адрес | Махсус счет хуҗасының исеме | Почта адресы | Төп дәүләт теркәү номеры | Салым түләүче ненң тәнгәллек номеры | ОКТМО | Исәпкә алу сәбәбе коды (КПП) | ДТИ теркәү көне | ДТИ теркәлү номеры | Хәбәр итү көне | КР фонды (махсус счет, төбәк операторы исемендәге махсус счет) | Фондны формалаштыру ысулын сайлау турында карар кабул итү турында милекчеләрнең гомуми җыелышы беркетмәсе көне | Махсус счетны ачу көне |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |

3 нче кушымта

Махсус счетлар реестры,
20___ елның «__» ________ торышына хисап

| Муниципаль берәмлек | Адрес | Махсус счет хуҗасының исеме | Махсус счет № | Ачылу көне | Ябылу көне | Банкның исеме | Банкның почта адресы | Банкның ИНН | Банкның КПП | Банкның ОГРН | Банкның БИК | Банкның корреспондент счеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |

4 нче кушымта

20___ елның « 01 » ________________ булган торышында капиталь ремонтка кертемнәр сыйфатында исәпләнгән, капиталь ремонт өчен кертемнәр сыйфатында күчкән акчалар, капиталь ремонт өчен махсус счеттан тотылган акчалар күләме турында, махсус счетта калган акчалар күләме турында, капиталь ремонт уздыруга займ һәм (яки) кредит шартнамәсе төзү турында белешмәләр

| Махсус счет хуҗасының оешту-хокук формасы (ТМШ/ТТК/ИК) | Махсус счет хуҗасының тулы исеме | Махсус исәп ачылган КФЙ | Махсус счет номеры | Махсус счет ачылган кредит оешмасы (банк) атамасы | КФЙ гомуми мәйданы, кв.м. | КФЙ торак һәм торак булмаган биналарның гомуми мәйданы, кв.м. | Капиталь ремонтка тариф, сум. | КФЙ капиталь ремонтына айлык кертем күләме, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |

| Капиталь ремонт фондын формалаштыра башлаганнан (беренче исәпләүдән) бирле хисап датасы буенча | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Капиталь ремонт өчен кертем сыйфатында исәпләнгән акчалар күләме турында белешмәләр, сум. | | | Капиталь ремонтка кертем сыйфатында күчкән акчалар күләме турында белешмәләр, сум. | | | Капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча бурыч күләме турында мәгълүмат, сум. | Махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акчалар күләме турында мәгълүмат, сум. | Махсус счетта калган акча күләме турында мәгълүмат*, сум. | Капиталь ремонт үткәрү өчен займ шартнамәсе һәм (яки) кредит шартнамәсе төзү турында белешмәләр | Кредит шартнамәсе буенча бурыч (арта баручы нәтиҗә белән) |
| Барлыгы исәпләнгән (11+12) | Капиталь ремонт өчен милекчеләрнең кертемнәре | Пеня лар | Барлыгы түләнгән (14+15) | Капиталь ремонт өчен милекчеләрнең кертемнәре | РФ Торак кодексының 170 ст. 1 өлеше нигезендә капиталь ремонт фондын барлыкка китерүче башка керемнәр | | | | | |
| 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |

| Ел башыннан хисап датасына кадәр | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ел башына калган акчалар күләме турында белешмәләр, сум. | Ел башыннан капиталь ремонт өчен кертемнәр сыйфатында исәпләнгән акчалар күләме турында мәгълүмат. | | | Ел башыннан капиталь ремонт өчен кертем сыйфатында күчкән акчалар күләме турында мәгълүмат. | | | Ел башыннан алып капиталь ремонтка кертемнәр буенча бурыч күләме турында мәгълүмат, сум. | Ел башыннан бирле махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акчалар күләме турында мәгълүмат, сум. |
| | Барлыгы исәпләнгән (23+24) | Капиталь ремонт өчен милекчеләрнең кертемнәре | Пенялар | Барлыгы түләнгән (26+27) | Капиталь ремонт өчен милекчеләрнең кертемнәре | РФ Торак кодексының 170 ст. 1 өлеше нигезендә капиталь ремонт фондын барлыкка китерүче башка керемнәр | | |
| 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |

* Мәгълүматлар актуаль, хисап кварталыннан соң килә торган айның 1 нче көненә (1 нче гыйнварга, 1 нче апрельгә, 1 нче июльгә, 1 нче октябрьгә) банкның расланган өземтәсе белән раслана.

5 нче кушымта

Капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайламаган күпфатирлы йорт турында мәгълүматлар, 20 ___ елның «__» ______булган торышында хисап

| № | Муниципаль берәмлек | Адрес | Идарәче оешманың оешу-хокук формасы | Идарәче оешманың тулы исеме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |